ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№187 от «23» 05 2024 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 19 июнендәге 387 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

"Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2023 елның 27 ноябрендәге 558-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, хокукый мониторинг тәртибендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 19 июнендәге "Җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль учреждениеләрнең ирекле (волонтерлык) эшчәнлекне оештыручылар, Ирекле (волонтерлык) оешмалар белән үзара хезмәттәшлек тәртибен раслау турында" 387 номерлы карарына (алга таба- Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карардагы Нигезләмәнең 15 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"15. Җирле үзидарә органнары ирекле (волонтерлык) эшчәнлегендә катнашучыларга "Коммерцияле булмаган оешмалар турында" 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы әлеге Федераль законда һәм Россия Федерациясенең, Россия Федерациясе субъектларының башка норматив хокукый актларында, муниципаль норматив хокукый актларда каралган формаларда. ярдәм күрсәтәләр.

Җирле үзидарә органнары тарафыннан ирекле (волонтерлык) эшчәнлектә катнашучыларга ярдәм түбәндәге формаларда башкарылырга мөмкин:

1) финанс ярдәме, шул исәптән грантлар һәм субсидияләр бирү;
2) оештыру ярдәме;
3) мәгълүмат ярдәме;
4) консультация ярдәме;
5) милек ярдәме, шул исәптән биналарны түләүсез файдалануга бирү;
6) методик ярдәм.

Ирекле (волонтерлык) эшчәнлегендә катнашучыларга ярдәм чаралары исемлеге җирле үзидарәнең вәкаләтле органы-Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан "Хәйрия эшчәнлеге һәм иреклелек (волонтерлык) турында" 1995 елның 11 августындагы 135-ФЗ номерлы Федераль законның 17.4 статьясының 2 пунктчасында каралган формаларны исәпкә алып билгеләнә.

Коммерция оешмалары булган ирекле (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручыларга финанс һәм милек ярдәме күрсәтү рөхсәт ителми.".

0000012177

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://mamadysh.tatarstan.ru/ / веб адрес буенча бастырып чыгарырга һәм Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Н.Ш.Фатыховка йөкләргә.

Җитәкче вазифаларын башкаручы

А.Х.Әгъләмов